СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД ИННОПОЛИС»
ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район, Республика
Татарстан, 420500

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ
«ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ»
СОВЕТЫ
Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

РЕШЕНИЕ КАРАР

13.06.2024 32-176

№

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пунктына ярашлы,

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Аерым салым түләүчеләргә исәпләнгән бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү, аны түләү һәм (яки) түләтү мөмкин булмаган, җирле салымнар суммалары өлешендә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 һәм (яки) 70 статьяларында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада физик затларның бурычы булуы.

2. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып:

1) әлеге карарның 1 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:

а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;

б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;

3) әлеге карарның 1 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу турында белешмәсе.

3. «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 07 апрелендәге 20-106 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) басылып чыккан көннән үз көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), һәм Иннополис шәһәре мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан ителергә тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшкуарлыкны үстерү буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
Иннополис шәһәре Мэры Р.Р. Шагалеев